**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 февраль № 85

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 гыйнвар, 3 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Ресубликасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегендә гражданнар акчасын җәлеп итүне гамәлгә кертү турындагы карарда гражданнардан җәлеп ителә торган акчаны тотуның тәгаен юнәлешләре һәм күләмнәре күрсәтелү;»;

өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле 5.1 нче пункт өстәргә:

«5.1. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары агымдагы елның 1 маена һәм 1 ноябренә

кадәр чираттагы ярты еллыкта гражданнардан җәлеп итү тәртибендә җыярга планлаштырыла торган акча күләмнәре, аннан файдалану юнәлешләре турында бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына мәгълүмат кертә.»;

6 нчы пункттагы «кварталы» сүзен «ярты еллыгы» сүзенә алыштырырга;

13 нче пункттагы «15 календарь көн» сүзләрен «15 эш көне» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 15.1 нче пункт өстәргә:

«15.1.Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы гражданнардан җәлеп ителгән һәм башка бюджетара трансфертлар керүне һәм аннан файдалануны билгеләнгән тәртиптә аерым исәпкә алуны тәэмин итә.»;

бу карарга теркәлгән кушымта редакциясендә бәян ителгән 3 нче кушымта өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\85.doc